**Республика Татарстан**
**Старо-Имянское сельское поселение Сармановского муниципального района**

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге**

**КАРАР**
**09.12.2021 г.**

**КАРАР**
**№37**

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең 2022 нче елга һәм 2023, 2024 нче еллар план чорына бюджеты турында**

"Россия Федерациясенлә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 нче статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы "Иске Имән авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы "Иске Имән авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

Статья 1

1.Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең 2022 нче елга бюджетының төп характеристикасын расларга:

1) Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджетының фаразланган гомуми керем күләме 3 263,0 мең сум күләмендә;
2) Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджетының гомуми чыгымнары күләме 3 263,0 мең сум;
3) Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджеты кытлыгы 0,0 мең сум.

2.Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең 2023 нче елга һәм 2024 нче елга бюджетының төп характеристиксын расларга:

1) Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең 2023 нче елга фаразланган кеременең гомуми күләме 3 344,6мең сум һәм 2024 нче елга 3 428,6 мең сум күләмендә;

2) 2023 нче елга гомуми чыгымнары күләме 3 344,6 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 90,0 мең сум күләменлә, һәм 2024 нче елга 3428,6 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвешә расланган чыгымнар 180,0 мең сум күләмендә.
3) Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджеты кытлыгы 2023 нче елга 0,0 мең сум һәм 2024 нче елга 0,0 мең сум.

3.Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең 2022 нче елга һәм 2023, 2024 нче еллар план чорына бюджет кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә расларга.

Статья 2

1.Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге 2023 нче елның 1 гыйнварына эчке муниципаль бурычының югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең муниципаль гарантияләре буенча буычының югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга.

2.Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге 2024 нче елның 1 гыйнварына эчке муниципаль бурычының югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең муниципаль гарантияләре буенча бурычының югары чиген 0,0 мең сум кләмендә расларга.

3.Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге 2025 нче елның 1 гыйнварына эчке муниципаль бурычының югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең муниципаль гарантияләре буенча буычының югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга.

Статья 3

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджетында 2022 нче елга һәм 2023, 2024 нче еллар план чорына фаразланган керем күләмен карарның 2 нче кушымтасы нигезендә исәпкә алырга.

Статья 4

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджетының 2022 елга һәм 2023, 2024 еллар план чорына чыгымнарының ведомство структурасын шушы карарның 3 нче кушымтасы нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (муниципаль программалары һәм программага карамаган эшчәнлек юнәлешләре), 2022 елга һәм 2023, 2024 еллар план чорына бюджет чыгымнары

классификациясенең чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне әлеге карарның 4 нче кушымта нигезендә расларга.
3. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен максатчан статьялар (Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге муниципаль программалары һәм программага карамаган эшчәнлек юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре, 2022 елга һәм 2023, 2024 еллар план чорына бюджет чыгымнары классификациясе бүлекләре, бүлекчәләре буенча бүлүне әлеге карарның 5 нче кушымта нигезендә расларга.
4. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджетының халык алдында норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлдерә торган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 2022 нче елга 0,0 мең сум, 2023 нче елга 0,0 мең сум, 2024 нче елга 0,0 мең сум күләмендә расларга.

Статья 5
1.Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджетының 2021 нче елга, төзелгән килешүләр нигезендә, мәдәният хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итү буенча шартлар тудыру буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен 1 685,3 мең сум, 2023 нче елга 1 750,4 мең сум, 2024 нче елга 1 818,5 мең сум күләмендә башка бюджетара трансфертлар күләмен расларга.
2. 2022 нче елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджетыннан башка бюджетара трансфертларны күчерү квартал саен башкарыла дип билгеләргә.

Статья 6
Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджетында Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы бюджетыннан алына торган акчаны исәпкә алырга:
1)2022 нче елга бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр – 2 6,6 мең сум, 2023 нче елга – 2 7,3 мең сум, 2024 нче елга – 28,1 мең сум;
2) 2022 нче елга хәрби комиссариатлары булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру өчен авыл җирлекләре бюджетларына субвенцияләр – 103,8 мең сум, 2023нче елга – 107,3 мең сум, 2024 нче елга- 111,2 мең сум.

Статья 7
1.
Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге муниципаль казна учреждениеләренә яңа функцияләр яисә вәкаләтләр бирү белән бәйле карарлар кабул итү очракларыннан тыш, Татарстан

Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары 2022 елда муниципаль хезмәткәрләр һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

Статья 8

1.Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге исеменнән төзелгән товарларга, эшләр башкаруга, хезмәт күрсәтүләргә муниципаль контрактларның 2021 елда түләнергә тиешле шартлары нигезендә түләнергә тиешле муниципаль контрактларның үтәлүенә файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләренең калган суммасыннан артмаган күләмдә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта, 2022 елда әлеге максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга юнәлдерелә.

Статья 9

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментының Сарман муниципаль районы буенча территориаль бүлеге төзелгән килешүләр нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыра.

Статья 10

Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" (PRAVO TATARSTAN. RU) һәм Татарстан Республикасы "Сарман муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

Статья 11

Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан көченә керә.

Статья 12

Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Иске Имән авыл җирлеге Советы рәисе: Р.Ә.Исламова